**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге**
**Советы**

422740, Әтнә муниципаль районы
Күәм авылы,
Х.Такташ урамы, 1/1
тел. 3-63-39, факс 3-63-39

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Совет Кубянского сельского**
**поселения**

422740, Атнинский муниципальный район
с.Кубян,
ул. Х.Такташа, 1/1
тел. 3-63-39, факс 3-63-39

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«9» ноябрь 2019 ел. № 8

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл җирлеге Әйшияз торак пунктында
гражданнарнын үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2019 елнын 29 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Әйшияз торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Әйшияз торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 29 ноябрь 2019 ел 18.00 сәг.тән 19.00 сәг.кадәр;
- уткәру урыны — Әйшияз авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт, Әйшияз КФҮ ;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 23 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Күәм авылы, Х.Такташ урамы, 1/1 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Әйшияз торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Әйшияз торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнар җыены турында һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Күәм авыл җирлеге Әйшияз торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу

акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Әйшияз авылы территориясен чистарту;
- Әйшияз авылы обелискын эшләү һәм урнаштыру.

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Күәм авылы, Х.Такташ ур., 1/1 йорт, Каенсар авылы, Мир ур.11 йорт, Дусым авылы, Ш.Камал ур.46 йорт, Әйшияз авылы Мәктәп ур.1 йортлардагы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карар, ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Күәм авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Гатауллин